СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-2 от «14» ноября 2025 г.

2014 елның 27 гыйнварендәге 7-28 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 25 декабрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы һәм муниципаль районның авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы инициативасы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы

карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2014 елның 27 гыйнварендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре муниципаль берәмлегеннән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 7-28 номерлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «"килеп туган гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чаралары уздыру һәм аларны үткәрүне оештыру турында карарлар кабул итү;»;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Мамадыш муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://madysh.tatarstan.ru веб адресында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль район Башлыгы В.И.Никитин

000115